**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА КУЛЬБАЕВО-МАРАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛБАЙ-МОРАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Колбай-Мораса **КАРАР**

«30» октябрь 2019 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлегенең Колбай-Мораса авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Колбай-Мораса авылы Ленин урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан Колбай-Мораса авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат районы Колбай-Мораса авылында Ленин һәм Заречный урамнарында яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2019 елның 12 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Колбай-Мораса авылы, Ленин урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авылының Мәктәп һәм Яшел урамнарында яшәүчеләрдән буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2019 елның 13 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Колбай-Мораса авылы, Ленин урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авылының Пионер һәм Тукай урамнарында яшәүчеләрдән буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2019 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Колбай-Мораса авылы, Ленин урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авылының Яр Буе, Мичурин, Бакча урамнарында яшәүчеләрдән буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Колбай-Мораса авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен бүләргә.

6. Колбай-Мораса авылында халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыруны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Колбай-Мораса авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Колбай-Мораса торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту.

- су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару.

«ӘЙЕ» «ЮК».

8. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Колбай-Мораса авыл җирлегенең Колбай-Мораса авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына кадәр10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы Г.Ф. Сафина